СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 ноябрь 2022 ел** **№68**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында” 2018 елның 30 апрелендәге 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 ел, 182 нче санлы «Татарстан Республикасында үз вәкәләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыкларының, муниципаль берәмлек башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында" карарына үзгәрешләр кертү турында” гы 17.09.2022 ел, 1015 санлы карары нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 30.04.2018 ел, № 122 карарына (204.09.2018 № 145, 16.01.2019 № 159, 30.09.2020 № 6, 17.10.2022 №63 карарлары редакциясендә) тәбәндәгн үзгүрешләрне кертергә:

- 1 пунктның 2 абзацында «11163» санын «12688» санына алыштырырга;

- 2 пункттагы 2.1 пунктчамсының 3 абзацында «6,72» санын «9,26» санына алыштырырга;

- 1 нчы кушымтада «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләүләре күләме» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 12 нче группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | 17390 |

- “Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләме” исемле 6 нчы кушымтаның 1 пунктында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

- “Муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе» исемле 11 нче кушымтаның 1 пунктындагы 6 пунктчада «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның үз көченә керү вакытын 2023 елның гыйнварыннан дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина